**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздыру турында**

Гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, халыкның йөрәк-кан тамырлары авырулары куркынычы турында хәбәрдарлыгы дәрәҗәсен күтәрү мәсьәләләренә җәмгыятьнең игътибарын җәлеп итү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай эчендә Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

бер ай эчендә Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларына Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционер җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында 2015 елда Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәшү елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 07 март
№ ПУ-261